**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**№ 139** **20 сентябрь 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Ивашкино авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 ел, № 67 - ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында " Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Ивашкино авыл җирлеге Уставы белән, Ивашкино авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 сентябрендәге 138 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында " карарын карап, Ивашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 18 сентябрендәге 12 номерлы " Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында " Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Ивашкино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән тыш, 2020 елда 400 сум

күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

-Ивашкино, Әккәрәй авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, юлларны грейдлаштыру, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, чыгымнар, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү); өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару(хезмәтләр күрсәтү)  өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару(хезмәтләр күрсәтү); өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, экспертиза һәм су анализы өчен түләү;

Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе өчен 50 метр күләмендә койма сатып алу;

- Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбенең подъезд юлын ремонтлау өчен 30 метрлы төзелеш материаллары сатып алу;

«ӘЙЕ» « ЮК»

3.Әлеге карарны «Безнен Чирмешән» район газетасында («Наш Черемшан») бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык, Ивашкино авыл җирлеге
Советы рәисе Н. Н. Ефимов